ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә:

а) унтугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) егерме җиденче абзацта "хуҗалык һәм башка эшчәнлек субъектлары" сүзләрен "юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар" сүзләренә алмаштырырга;

в) кырыгынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"файдалана алу мөмкинлеге булган иң яхшы технология – продукция (товарлар) җитештерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү технологиясе, ул, куллану өчен техник мөмкинлекләр булганда, фән һәм техниканың заманча казанышларына һәм әйләнә-тирә мохитне саклау максатларына ирешү критерийлары бергәлегенә нигезләнеп билгеләнә;";

г) кырык өченче абзацта "иҗтимагый һәм коммерциягә карамаган башка берләшмәләрнең," сүзләрен "иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган оешмаларның" сүзләренә алмаштырырга;

д) алтмышынчы абзацта "чүпләндерүгә," сүзен төшереп калдырырга;

е) алтмыш бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“технологик нормативлар – пычраткыч матдәләрне һавага чыгаруның һәм чыгарып ташлауның, физик йогынтыларның технологик күрсәткечләр кулланып билгеләнә торган мөмкин нормативлары;”;

ж) алтмыш алтынчы абзацта “табигатьне саклау нормативлары” сүзләрен “әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге нормативлар” сүзләренә алмаштырырга;

з) алтмыш җиденче абзацта “хуҗалык һәм башка эшчәнлек субъекты” сүзләрен “юридик зат яисә индивидуаль эшкуар” сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда:

а) унбишенче абзацта “гамәлдәге” сүзен “мөмкин булган” сүзләренә алмаштырырга;

б) уналтынчы абзацта “иҗтимагый һәм коммерциягә карамаган башка берләшмәләрнең” сүзләрен “иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган оешмаларның” сүзләренә алмаштырырга;

в) унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт җайга салуының хуҗалык эшчәнлеге һәм (яисә) башка төрле эшчәнлек башкаручы яисә шундый эшчәнлек башкаруны планлаштыручы юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга карата кулланыла торган чараларын билгеләүгә гомуми һәм индивидуаль алымнарның бергәлеген тәэмин итү;”;

г) егерме өченче абзацта “иҗтимагый һәм коммерциягә карамаган башка берләшмәләрнең” сүзләрен “иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган оешмаларның” сүзләренә алмаштырырга;

д) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“әйләнә-тирә мохитне пычратуга китергән яисә китерергә мөмкин хуҗалык эшчәнлеге һәм (яисә) башка төрле эшчәнлекне башкаручы юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны булдырмау һәм (яисә) киметү, әлеге йогынтыдан килгән зыяннарны бетерү чараларын финанслауның мәҗбүрилеге.”;

3) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4 статья. **Әйләнә-тирә мохитне саклау объектлары**

Әйләнә-тирә мохитне пычратудан, ярлыландырудан, деградацияләүдән, бозудан, юкка чыгарудан, хуҗалык эшчәнлегенең һәм (яисә) башка эшчәнлекнең бүтән тискәре йогынтысыннан саклау объектлары табигать мохите компонентларыннан, табигать объектларыннан һәм табигать комплексларыннан гыйбарәт.”;

4) 8 статьяның 1 өлешендә:

а) унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган һәм региональ дәүләт экология күзәтчелегендә торырга тиешле объектларның дәүләт исәбен алып бару;”;

б) ундүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

5) III кисәкнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“III КИСӘК

**ЭКОЛОГИЯ ӨЛКӘСЕНДӘ ГРАЖДАННАРНЫҢ, ИҖТИМАГЫЙ БЕРЛӘШМӘЛӘРНЕҢ ҺӘМ КОММЕРЦИЯГӘ КАРАМАГАН ОЕШМАЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ**”;

6) 10 статьяның 2 өлешендәге икенче абзацта “, фондлар” сүзен төшереп калдырырга;

7) 11 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“11 статья. **Экология өлкәсендә иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган оешмаларның хокуклары һәм бурычлары**”;

б) 1 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциягә карамаган оешмалар әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә эшчәнлек алып барырга хокуклы, шул исәптән:”;

в) 2 өлештә “Иҗтимагый һәм коммерциягә карамаган башка берләшмәләр” сүзләрен “Иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциягә карамаган оешмалар” сүзләренә алмаштырырга;

8) 12 статьяда:

а) 1 өлештә “иҗтимагый берләшмәләргә һәм коммерциягә карамаган башка берләшмәләргә” сүзләрен “иҗтимагый берләшмәләргә һәм коммерциягә карамаган оешмаларга” сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Вазыйфаи затлар гражданнарга, шулай ук иҗтимагый берләшмәләргә һәм коммерциягә карамаган оешмаларга экология өлкәсендә законнарда каралган хокукларын гамәлгә ашыруга каршылык тудырган очракта, күрсәтелгән вазыйфаи затлар билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.”;

9) 23 статьяның 1 өлешендә “хуҗалык һәм башка эшчәнлек субъектлары” сүзләрен “юридик затлар яисә индивидуаль эшкуарлар” сүзләренә алмаштырырга;

10) 28 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“мөмкин булган иң яхшы технологияләрнең технологик күрсәткечләре.”;

11) 31 статьяның 1 өлешендә “хуҗалык һәм башка эшчәнлек субъектларының” сүзләрен “юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның” сүзләренә алмаштырырга;

12) 47 статьяда:

а) 1 өлештә “экология өлкәсендәге законнарда билгеләнгән” сүзләрен “әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарда билгеләнгән” сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә I, II, III категорияләргә кертелгән объектларда хуҗалык эшчәнлеге һәм (яисә) башка эшчәнлек алып бара торган юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар җитештерү экология контроле программасын эшлиләр һәм раслыйлар, билгеләнгән таләпләр нигезендә җитештерү экология контроле уздыралар, мәгълүматны документлаштыралар һәм җитештерү экология контроле уздыру нәтиҗәләре буенча алынган белешмәләрне саклыйлар.”;

13) 49 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“49 статья. **Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларны дәүләт исәбенә алу**

1. Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларны дәүләт исәбенә алу әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектлар турында дөрес мәгълүмат алу, мөмкин булган иң яхшы технологияләрне куллану өлкәләрен билгеләү, программалы-максатчан планлаштыру ысулларын куллану максатларында, шулай ук дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруны планлаштыру максатларында башкарыла.

2. Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларны дәүләт исәбенә алу әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларның дәүләт реестрын алып бару рәвешендә башкарыла, ул әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларның федераль дәүләт реестрыннан һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларның региональ дәүләт реестрларыннан гыйбарәт.”;

14) 60 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

15) 65 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“65 статья. **Әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында башкарыла торган хуҗалык эшчәнлегенә һәм (яисә) башка эшчәнлеккә дәүләт ярдәме**

1. Дәүләт юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында башкарыла торган хуҗалык эшчәнлегенә һәм (яисә) башка эшчәнлеккә ярдәм күрсәтә.

2. Әйләнә-тирә мохитне саклау максатларындагы хуҗалык эшчәнлегенә һәм (яисә) башка эшчәнлеккә дәүләт ярдәме түбәндәге юнәлешләр буенча күрсәтелергә мөмкин:

1) әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясауны киметү буенча файдалана алу мөмкинлеге булган иң яхшы технологияләрне кертүгә һәм башка чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтү;

2) әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясауны киметү гамәлләренә мәгълүмати ярдәм итүгә булышлык күрсәтү;

3) торгызыла торган энергия чыганакларыннан, икенчел ресурслардан файдалануга, әйләнә-тирә мохитнең пычрануын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча нәтиҗәле башка чараларны гамәлгә ашыруны тикшереп торуның яңа ысулларын эшләүгә Россия Федерациясе законнары нигезендә булышлык күрсәтү.”;

16) 66 статьяның 1 өлешендә “хуҗалык һәм башка эшчәнлек субъектларының” сүзләрен “юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның” сүзләренә алмаштырырга;

17) 83 статьяның 6 өлешендә “техник” сүзен “технологик” сүзенә алмаштырырга, “чыгарып ташлауларның һәм” сүзләреннән соң “(яисә)” сүзен өстәргә;

18) 94 статьяның 2 өлешендә “күмү урыннарын” сүзләрен “урнаштыру объектларын” сүзләренә алмаштырырга;

19) 95 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Су баса торган зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре дәүләт ихтыяҗлары өчен алынган очракта, кишәрлекләрне алу җир законнары һәм граждан законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.”;

20) 98 статьяның 13 өлешендәге 2 пунктында “күмү урыннары” сүзләрен “урнаштыру объектлары” сүзләренә алмаштырырга;

21) 99 статьяның 2 өлешендә “махсус сакланылучы табигать территорияләре турындагы федераль законнар һәм әлеге Кодекс” сүзләрен “махсус сакланылучы табигать территорияләре турындагы законнар, мәдәни мирас объектлары турындагы законнар һәм әлеге Кодекс” сүзләренә алмаштырырга;

22) 102 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Җир ресурсларын һәм туфракны саклауның максатлары җирләрне һәм туфракны пычратуны, ярлыландыруны, деградацияләүне, бозуны, юкка чыгаруны, җиргә һәм туфракка башка төрле тискәре йогынтыны булдырмаудан һәм бетерүдән, шулай ук җирләрдән, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшырту өчен, рациональ файдалануны тәэмин итүдән гыйбарәт.”;

б) 2 өлештә:

2 пунктта “җитештерү һәм куллану калдыклары белән чүпләнүдән һәм туфрак деградациясе барлыкка килерлек башка тискәре (зарарлы) йогынтылардан” сүзләрен “җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычранудан һәм туфрак деградациясе барлыкка килә торган башка тискәре йогынтылардан” сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта “һәм чүпләүдән” сүзләрен төшереп калдырырга;

23) 119 статьяның 3 өлешендә “вакытлы” сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) “Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2010 елның 16 маендагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 17 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 5 (I өлеш);

2) “Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2013 елның 12 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пунктының “б” пунктчасын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1; 2014, № 5).

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 елның 11 апреле
№ 23-ТРЗ